ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:
«41) җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

2) 16 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 36 пункт өстәргә:
«36) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

3) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 45 пункт өстәргә:

«45) шәһәр округы милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 106-ТРЗ